СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

08.11.2024 Баулы шәһәре № 274

Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы «Баулы муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 21 сентябрендәге 820 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» Карары нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 20 апрелендәге 150 номерлы «Баулы муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына (Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 28 сентябрендәге 177 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 275 номерлы, 2022 елның 22 февралендәге 104 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 152 номерлы, 2024 елның 113 июнендәге 258 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи оклад күләме, бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган Баулы муниципаль районы муниципаль берәмлегендә Бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркатибенең 13 990 сумлык вазыйфаи оклады күләменә карап исәпләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
Баулы муниципаль район
Советы Рәисе вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Хәмидуллин